# Милләт җанлы әдипләр бездә кунакта

**Үткән җомга көнне Ульяновск шәһәренең 17 нче санлы милли китапханәсендә Казаннан килгән иҗат әһелләре - мәшһүр татар язучысы, шагыйрь, прозаик һәм публицист, Муса Җәлил премиясе, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ркаил Зәйдулла, татар шагыйре, журналист һәм публицист, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, Муса Җәлил премиясе лауреаты Газинур Морат һәм «Идел» журналының баш мөхәррире Радик Сабиров белән очрашу булып узды.**



Истәлекле вә мәртәбәле очрашуны Ульяновск өлкә татар милли-мәдәни автономиясе рәисе Рамис Сафин ачып җибәрде. Ул ерак юлны якын итеп килгән каләм ияләренә рәхмәт сүзләрен ирештереп, китапханә мөдире Ольга Юрловага - Бөтендөнья татар конгрессының Мактау грамотасын, ә «Идел» журналы редакциясенә «Сембер-Ульяновск төбәге татарлары» энциклопедиясен тапшырды. Аннары очрашуда катнашучыларны «Идел»нең баш редакторы Радик Сабиров сәламләде. Ул хәзерге яшьләрнең китап, газета-журналлар укымавы, көне-төне интернетта утыруы һәм шул рәвешле ана теленнән читләшә баруы турында ачынып сөйләде. Радик әфәнде Сембер төбәге татар язучыларын «Идел» белән хезмәттәшлек итәргә



чакырды. Әсәрләрегез яхшы язылган булсын - төп таләбебез менә шул, диде ул. Яңа гына, ягъни быелның язында Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган талантлы шагыйрь, унбер китап авторы Газинур Морат исә истәлекләре белән дә уртаклашты, фәлсәфи уй-фикерләре белән дә бүлеште, күңел кылларын тибрәндерерлек милли рухлы шигырьләрен дә яңгыратты.

- Кандалый хәзрәтләренең якташлары белән күрешүемә чиксез шатмын. Сембер төбәге - минем өчен бик тә кадерле як ул. Моннан кырык ел элек, Казан университетында укыган вакытта Иске Кулатка районында мишәр фольклорын җыеп йөргән идек. Көн саен кич белән авылларда концерт куюыбыз әле дә хәтеремдә. Ул чакларны бүген дә сагынып искә алам. Сембер җире татар әдәбиятына Габделҗаббар Кандалый, Ибраһим Нуруллин һәм Равил Әмирхан кебек олпат шәхесләрне биргән. Хәзерге вакытта сезнең җирлектә яшәп иҗат итүче шагыйрьләр Иделбикә, Равил Шәфигуллин һәм Шәфикъ Иматдиновның әсәрләрен дә югары бәялибез. Сер итеп кенә әйтәм, тиздән Татарстан китап нәшриятында Шәфикъ аганың җыентыгы басылып чыгачак. Шуны онытмагыз: адәм баласын бары тик әдәби әсәр тәрбияли, яхшылыкка өйрәтә. Китап калыр, юкка чыкмас дип уйлыйм, чөнки анда халык фикере, хәтере саклана,- диде Газинур Морат.

Милләт язмышы турында кайгыртып, татар өчен җан атып яшәүче олпат шагыйрь Ркаил Зәйдулла да үзенең чыгышында күпләрне борчыган сорауларга җавап бирде.

- Сембер - гаҗәеп матур шәһәр, безнең Казаннан аермалы буларак, биредә иске йортлар сакланган әле. Сезнең калагыз революциягә кадәр татарның мәдәният һәм мәгърифәтчелек үзәге саналган. Данлыклы якташыгыз Кандалый - чын татар теле белән беренче булып язган шагыйрь. Бөек Тукаебыз аның үрнәгендә яза башлаган. Биредә шулай ук данлыклы Акчуриннар



нәселен дә телгә алып үтү урынлы булыр. Алар милләтебез үсешенә бәһасез өлеш керткән. Тиздән татар үлә, дип ятудан бернинди файда юк. Милләтне юкка чыгудан коткару өчен гаиләдә бала-оныкларны татарча тәрбияләргә, сабыйларга саф татарча исемнәр кушарга кирәк. Әгәр мәктәпләрдә дин дәресләре кертәләр икән, балаларны аерым-аерым укыту чарасын күрсеннәр. Бәлки, теләүчеләр өчен факультативлар оештырыргадыр... Бүген күп нәрсә үзебездән тора бит. Гаиләдә, урамда татарча сөйләшүне тыймыйлар, көчләп чукындыручы юк. Телне, милләтне, динне саклап калу өчен шартлар җитәрлек, әйдәгез, мөмкинлектән файдаланып калыйк,- диде Ркаил Зәйдулла, семберлеләргә мөрәҗәгать итеп.

Мөгаллимә Гөлфәрия Латыпова, Сембер татар сәхнәсе йолдызлары Алсу һәм Айгөл Альметовалар, каләм ияләре Иделбикә, Шәфикъ Иматдинов, Сәгыйть Бәдретдинов әдәби кичәне шигырьләре, моңлы җырлары һәм эчтәлекле чыгышлары белән бизәделәр. Алар әлеге очрашуны оештыру максатында зур тырышлык куйган өчен китапханәче Гөлфия Сәмигуллинага рәхмәт белдерделәр.

**Исхак ХӘЛИМОВ.**